Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Югары Кондрата авыл җирлеге составына керүче
Югары Кондрата авылы торак пунктында гражданнар җыены
Карары

2026 елның 25 июненнән №5

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, «2026 елның 25 июнендә 2025 елның 14 ноябрендәге карар мәсьәләсен үзгәртүгә ризамы Сез?» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге составына керүче Югары Кондрата авылы торак пунктында гражданнар җыенында кабул ителгән, һәм 2026 елда алынган үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
- «су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (Югары Кондрата авылында су җыю манарасы астына нигез салу)»;
- «торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунтлау һәм грейдерлау, вак таш салу, шартнамә буенча эш өчен түләү)», Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге составына керүче Югары Кондрата авылы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге составына керүче Югары Кондрата авылында гражданнар җыенында кабул ителгән 2025 елның 14 ноябрендәге карар мәсьәләсен үзгәртергә һәм 2026 елда алынган үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (Югары Кондрата авылында су җыю манарасы астына нигез салу);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунтлау һәм грейдерлау, вак таш салу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү)».

2. Әлеге карарны Югары Кондрата авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Чистай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районының Югары Кондрата
авыл җирлеге башлыгы А. А. Журавлев